# Җөмләдә сүзләр бәйләнеше

**8нче сыйныф татар төркеме**


Сүзләр бәйләнеше
тезүле
ияртүле
Тиңдәш кисәкләр арасында
Кимендә 2 мөстәкыйль сүзнең үзара бәйләнешкә керүе. Сүзтезмә.

## Текстны укыгыз. Бер-берсенә бәйләнгән, ияргән сүзләрне язып алыгыз.

**Р. Миңнуллин. Мин кулыма китап алдым.**

- (1) Без – китаплы халык. (2) Татар халкы гыйлемле булган, китап укыган. (3) Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән кулъязма китаплар шул хакта сөйли. (4) Кулъязмаларны күчереп язучы осталар барлыкка килгән. (5) Хәзергечә әйтсәк, китапларны тиражлаучылар була.
- (6) Аннан басма китаплар чоры башланган. (7) Безнең әби-бабайларыбыз үз телләрендә белем алганнар, шул ук вакытта фарсыча да, гарәпчә дә белгәннәр. (8) Шунысы мөһим: без үзебез генә белемле булып калмаганбыз, мәгърифәт нурларын башка тугандаш халыкларга да таратканбыз. (9) Якын-тирәдә генә түгел, Урта Азия чүлләренә, далаларына кадәр үк барып җиткәнбез. (10) Бу да халкыбызның игелекле хезмәтләреннән саналырга тиеш.

# Сүзтезмә-кимендә 2 мөстәкыйль сүзнең үзара бәйләнешкә керүе

- Китаплы_халык-нинди халык?
- Татар_халкы-кайсы халык?
- Китап_укыган- нәрсә укыган?
- Бүгенге_көнгә- кайсы көнгә?
- язучы  осталар-нинди осталар?
- Кульъязмаларны   күчереп-нәрсәне күчереп?
- халыкларга да тараткanбыз- кемгә тараткanбыз?
- далаларына кадәр барып җиткәнбез- кая барып җиткәнбез?
- Безнең әби-бабайларыбыз - кемнең әби-бабайлары?
- игелекле_***хезмәтләреннән***- нинди хезмәтләреннән?
- ***хезмәтләреннән*** саналырга тиеш- нәрсәдән саналырга тиеш?

# Сүзтезмә төрләре

Китаплы_халык-нинди халык?

Китаплы – ияручe сүз

Халык- иярт үче сүз. Иярт үче сүз исем, димәк бу **исем сүзтезмә.**

Иярт үче сүзгә карап сүзтезмәләр нинди була? Сүзләрдән сүзтезмә барлыкка килсен өчен нинди чаралар кирәк?

Шул сорауларга җавап эзләрбез.

# Сүзтезмә төрләре

**Бирелгән сүзтезмәләрнең төрләрен билгеләгез, бәйләүче чараларны билгеләгез.**

**Һәрвакыт ягымлы-**

**Кояшлы иртә**

**Көн саен эшли**

**Арттан икенче**

**Бездән якын**

**Кызларның икесе**

**Тиз йөгерү**

**Алманың бусы**

**Дустым белән очрашабыз**

**Мәктәпкә кадәр ерак**

**Энемне озаттым**


**Әбием кебек кадерле**



Сүзтезмә төрләре
исем
сан
рәвеш
фигыль
сыйфат
алмашлык

# Бәйләүче чаралар

- Килеш кушымчалары
- Бәйлек һәм бәйлек сүзләр
- Сүз тәртибе (янәшә килү)


Сүзләр бәйләнеше
тезүле
ияртүле